ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8 статья. **Җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү**

1. Җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү федераль законнарда, әлеге Кодекста һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләреннән тыш, бер категориядән

икенче категориягә күчерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләренә, федераль милектәге җирләрдән тыш, кагылышлы җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы акт авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү каралган Татарстан Республикасы законы нигезендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан кабул ителә.

4. Авыл хуҗалыгы кырлары җирләрен яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү каралган Татарстан Республикасы законы проекты, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелү белән бер үк вакытта, бәяләмә алу өчен, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына җибәрелә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. 2026 елның 1 мартына кадәр кергән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориягә күчерү турында үтенечнамәләр һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү турында үтенечнамәләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән тәртиптә карала.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 19 февраль
№ 7-ТРЗ